**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 10 сентябрь | № 634

г. Казань

Питрәч муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Компаньён-EV» ҖЧҖнең Питрәч муниципаль районында урнашкан, «Компаньён-EV» ҖЧҖ милкендә булган 12,4912 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү, шул исәптән 16:33:080712:49 кадастр саны белән 10,4704 гектар складлар урнаштыру өчен, 16:33:080712:51 кадастр саны белән 1,119 гектар автотранспортка хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру өчен, 16:33:080712:46 кадастр саны белән 0,9018 гектар коммуналь хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру өчен, турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков